| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | с. Тюлячи | КАРАР |
| «25» марта 2010г. | | № 108 |

Административ комиссиянең яңа составын һәм аның эш нигезләмәсен яңа редакциядә раслау турында

Татарстан Республикасы юстиция министрының 2010 елның 16 мартындагы 01-11/866 номерлы хаты нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы административ комиссиясе составын 1 номерлы кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы административ комиссиясенең эш регламентын яңа редакциядә расларга (2 номерлы кушымта).

3. "Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы административ комиссиясе турында" Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2006 елның 13 мартындагы 24 номерлы карары административ комиссия составын һәм эш регламентын раслау өлешендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең "Аерым комиссияләр составына үзгәрешләр кертү турында" 2006 елның 29 июнендәге 130 номерлы карары административ комиссия составына үзгәрешләр кертү өлешендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең "Район Башкарма комитетының кайбер консультатив һәм киңәшмә органнары составына үзгәрешләр кертү турында" 2006 елның 21 ноябрендәге 252 номерлы карарын административ комиссия составына үзгәрешләр кертү өлешендә, "Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы административ комиссиясенең яңа составын раслау турында" Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручының 2009 елның 27 августындагы 184 номерлы карары, "Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы административ комиссиясенең эш регламентына өстәмә кертү турында" Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручының 2009 елның 30 сентябрендәге 234 номерлы карары, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручының "Теләче муниципаль районы административ комиссиясе составына үзгәреш кертү турында" 2009 елның 25 ноябрендәге 299 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Н. Зәйнетдиновка йөкләргә.

Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы А.Х. Хакимов

Кушымта № 1

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручының
2010 елның 25 мартындагы
карары белән расланды № 108

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы**
**Административ комиссиясе составы**

Комиссия рәисе:

Зәйнетдинов И.Н. - район Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары.

Комиссия рәисе урынбасары:

Вәлеев Ф.С. - район Башкарма комитетының инфраструктур үсеш бүлеге башлыгы.

Җаваплы сәркатип:

Фәсхиева Р.Н. -

Комиссия әгъзалары:

Зинатуллин И.З. - РФ Эчке эшләр министрлыгының ТР буенча Теләче районы эчке эшләр бүлеге башлыгы урынбасары(килешү буенча);

Хәкимуллин Л.М. - РФ ЭЭМ ТР буенча ДЯК Теләче бүлеге башлыгы (килешү буенча);

Миннеханова Л.И. - Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының Теләче муниципаль районы буенча җирле үзидарә органы эшчәнлегенә хокукый ярдәм күрсәтү бүлегенең әйдәп баручы белгеч-эксперты (килешү буенча);

Егоров Ю.Н. - Теләче авыл Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча).

Кушымта № 2

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручының
2010 елның 25 мартындагы
карары белән расланды № 108

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы**
**Административ комиссиясенең эш регламенты**

Әлеге Регламент Теләче муниципаль районы административ комиссиясенең эш тәртибен (алга таба - административ комиссия) билгели.

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Административ комиссия Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе карары белән төзелде.

1.2. Административ комиссия үз вәкаләтләрен Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы, Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы, "Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - Татарстан Республикасы Законы) һәм Теләче муниципаль районының җирле үзидарә органнары муниципаль хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашыра.

1.3. Административ комиссия Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар турында кодексында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау өчен төзелә торган даими эшләүче коллегиаль орган булып тора һәм Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы чикләрендә эшли.

1.4. Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы һәм Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә һәр эшне һәрьяклап, тулы, объектив һәм вакытында карау, чыгарылган карарны үтәүне тәэмин итү, шулай ук административ хокук бозуларны кисәтү административ комиссиянең бурычы булып тора.

1.5. Административ комиссиянең вәкаләтләре вакыты әлеге административ комиссиянең беренче утырышыннан Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты вәкаләтләре срогыннан башлана. Күрсәтелгән вакыт үткәннән соң административ комиссия үз вәкаләтләрен яңа составның административ комиссиясенең беренче утырышы көненә кадәр гамәлгә ашыруны дәвам итә.

1.6. Административ комиссия әгъзасы вәкаләтләре Татарстан Республикасы Законында каралган очракларда вакытыннан алда туктатыла.

1.7. Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты административ комиссиянең яңа әгъзасын административ комиссия әгъзасы урынына административ комиссия әгъзасының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында карар кабул ителгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча билгеләп куярга тиеш.

1.8. Административ комиссиянең тулы исеме булган мөһере бар.

## 2. Административ комиссия эшен оештыру

2.1. Административ комиссия административ комиссия рәисеннән, рәис урынбасарыннан, җаваплы сәркатибеннән һәм административ комиссия әгъзаларыннан (алга таба - административ комиссия әгъзалары) тора, алар Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе карары белән билгеләнә.

2.2. Административ комиссия әгъзалары үз вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Законы нигезендә гамәлгә ашыралар.

2.3. Административ комиссиянең персональ һәм санлы составы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 5 кешедән дә ким булмаган карары белән билгеләнә һәм исәп-хисап саны булырга тиеш.

2.4. Даими штат нигезендә административ комиссия составына административ комиссиянең җаваплы секретаре керә. Административ комиссиянең башка әгъзалары административ комиссиядә җәмәгать башлангычларында эшли.

2.5. Административ комиссия рәисе рәис урынбасары һәм административ комиссиянең җаваплы секретаре арасындагы вазыйфаларны бүлә, аларның функцияләрен Татарстан Республикасы Законы белән бирелгән вәкаләтләр чикләрендә билгели.

2.6. Административ комиссия рәисе административ комиссия әгъзаларының, шулай ук административ комиссия рәисе урынбасарының һәм җаваплы секретаренең квалификациясен күтәрү эшен оештыра.

2.7. Административ комиссия килүчеләрне кабул итә ала. Килүчеләрне кабул итү тәртибе административ комиссия рәисе боерыгы белән билгеләнә.

2.8. Административ комиссия адресына гражданнардан һәм юридик затлардан кергән шикаятьләр һәм мөрәҗәгатьләр гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда карала.

2.9. Административ комиссиягә кергән һәм аның тарафыннан каралган материаллар административ хокук бозулар буенча барлык эшләр формалаштырыла һәм административ комиссиядә саклана. Бу эшләр 3 ел дәвамында район Башкарма комитетының архив бүлегенә тапшырыла.

## 3. Административ комиссия утырышын чакыру һәм уздыру тәртибе

3.1. Административ хокук бозулар турында эшләрне карау

административ комиссия тарафыннан Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3.2. Административ хокук бозулар турындагы эшләр административ комиссия утырышларында карала. Административ комиссия утырышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында карар аның рәисе тарафыннан, ә ул булмаганда - рәис урынбасары тарафыннан административ хокук бозулар турында беркетмәләр һәм башка материаллар кергән очракта кабул ителә, ләкин аена кимендә бер тапкыр.

3.3. Административ комиссия утырышлары һәр шимбә көнне 9.00 сәгатьтә Теләче ав., Ленин ур., 40 й. адресы буенча үткәрелә.

3.4. Административ комиссиянең җаваплы секретаре административ комиссия утырышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында административ комиссия утырышына кадәр кимендә 3 көн алдан хәбәр итә.

3.5. Административ комиссия утырышында катнашу мөмкин булмаган очракта, рәис, рәис урынбасары һәм комиссия әгъзалары бу хакта, кагыйдә буларак, административ комиссия утырышына кадәр 2 эш көне эчендә хәбәр итәргә тиешләр.

3.6. Административ комиссия утырышы, әгәр анда административ комиссия әгъзаларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы була.

3.7. Административ хокук бозу турындагы эш буенча карар, билгеләмә утырышта катнашучы административ комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

## 4. Административ җәза бирү турындагы карарны үтәү

4.1. Административ комиссия тарафыннан чыгарылган карарлар Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы нигезендә үтәлә.

4.2. Административ комиссия тарафыннан чыгарылган карарларның, билгеләмәләрнең һәм күрсәтмәләрнең үтәлешен административ комиссиянең җаваплы сәркатибе контрольдә тота.

## 5. Административ хокук бозуларны профилактикалау

5.1. Административ хокук бозуларны кисәтү максатларында административ комиссия эчке эшләр органнары, суд приставлары федераль хезмәте идарәсенең территориаль бүлекләре, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы, башка органнар һәм иҗтимагый берләшмәләр белән үз эшчәнлеген координацияли.

5.2. Административ комиссия рәис раслаган график нигезендә күчмә утырышлар үткәрә, шул исәптән муниципаль район җирлекләре дә.

5.3. Административ комиссия үз эшчәнлеген массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту һәм халык арасында аңлату эшләре алып бару юлы белән профилактик эш алып бара.